ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

9 декабрь, 2021 ел № 10/7

Шәһәр Советының 2020 елның 28 маендагы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмаларга, Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез милеккә караган муниципаль милекне арендалау килешүләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына карата төзелгән җир участогы арендалау килешүләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына аренда килешүләре буенча аренда түләвенә ташлама билгеләү турында» 39/5 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

«Социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар реестры турында» 2021 елның 30 июлендәге 1290 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2020 елның 28 маендагы «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмаларга, Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез милеккә караган муниципаль милекне арендалау килешүләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына карата төзелгән җир участогы арендалау килешүләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына аренда килешүләре буенча аренда түләвенә ташлама билгеләү турында» 39/5 номерлы Карарына (Шәһәр Советының 2021 елның 18 мартындагы 6/9 номерлы Карары редакциясендә), 2.1. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2.1. Ташлама «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәл яки югары әзерлек режимын кертү турында

Карар кабул ителгәнче, «Социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар реестры турында» 2021 елның 30 июлендәге 1290 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмалар белән төзелгән аренда килешүләре буенча, Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлләр режимы кертелгән датага аренда килешүе нигезендә узган чор өчен аренда түләве буенча бурычлары булмаганда бирелә».

2. Әлеге Карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев